ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОВОИЛЬМОВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Улица Советская, дом 32,
село Новое Ильмово, 422477
ИНН 1617003162

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЯНА
ЭЛМЕЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Совет урамы, 32 нче йорт,
Яңа Элмәле авылы, 422477

Тел.: (84375) 3-62-02, 3-62-03, факс: (84375) 3-62-02, e-mail: Nilm.Drz@tatar.ru,

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.04.2019 года № 10

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба - 2006 елның 2 маендагы 59 – ФЗ номерлы федераль закон), «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге башкарма комитеты карарына _ Татарстан Республикасы Хөкүмәте Документлар ТР Хөкүмәте карарлары ТР Хөкүмәте карарлары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Башкарма комитетында (яңа редакциядә) гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау регламентын раслау турында» 2019 ел, 4нче февраль, №4 түбәндәге үзгәрешләрне кертәргә:

1) **4 пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка игълан ителгәннән соң) үз көченә керә.»;

2) Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Яңа Элмәле авыл җирлеге Башкарма комитетында гражданнар мөрәҗәгатьләрен карау Регламентында:

**6.1 пунктта:**

6.1 пунктындагы бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«әлеге Регламентның 4 бүлегендәге очраклардан тыш, мөрәҗәгатьтә куелган мәсьәләләрнең асылы буенча язмача җавап алырга, ә әлеге Регламентның 4.1 пунктындагы 8 пунктчасында каралган очракта, аны бирү турында үтенеч белән мөрәҗәгать итү нигезендә, дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка язма мөрәҗәгатьне яңадан рәсмиләштерү турында хәбәрнамә алырга;»;

сигезенче абзацны төшереп калдырырга;

**7.5.6 пунктында** "миграция өлкәсендә хокук куллану функцияләрен, контроль, күзәтчелек һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтү функцияләрен гамәлгә ашыра торган башкарма хакимият федераль органының территориаль органы" сүзләрен «Эчке эшләр өлкәсендә башкарма хакимиятнең федераль органы территориаль органы»сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында авыл җирлеге бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

Яңа Элмәле авыл җирлеге башлыгы
вазыйфасын башкаручы

Мискин В.